ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасал авыл җирлегенең Шәпкино авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2023 елның 8 декабре № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Янһгасал авыл җирлегенең Шәпкино авылында гражданнар җыены:

1.2024 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Янгасал авыл җирлегенең Шапкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (шул исәптән вак таш сатып алу, ташу һәм салу, Төньяк урамында су агымы торбаларын урнаштыру, юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (шул исәптән җәйге вакытта территорияне кисү, трактор өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (шул исәптән кисү, куаклардан чистарту, агачларны йоклату, транспорт хезмәтләре).

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

- ТР Кама Тамагы районы Олы Яңасала авылы, Үзәк урам, 1 йорт;

- ТР Кама Тамагы районы Шапкино авылы, Клуб урамы, 14 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы

Яңасал авыл җирлеге башлыгы И. Х. Шиһабеев